ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2023 Балык Бистәсе штп. № 440пи

**2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак йорт милекчеләре өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлешенә туры китереп, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 06.04.2018 №213/пр Әмере белән расланган «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында», «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы белән карар бирәм:

1. 2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак йорт хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексын 5 процент күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов